ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраль 2020 ел № 851

Башкарма комитетның «2016-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында» 2015 елның 29 декабрендәге 7510 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2016-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында» 2015 елның 29 декабрендәге 7510 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 28 мартындагы 1659 номерлы, 2017 елның 6 июлендәге 4046 номерлы, 2018 елның 29 мартындагы 1694 номерлы, 2018 елның 28 апрелендәге 2392 номерлы, 2018 елның 17 декабрендәге 7557 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы 1606 номерлы, 2019 елның 2 августындагы 3972 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13, «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге өлкәсендәге башка мәсьәләләр» 03.14, «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына 2016 елда – 19 884,35 мең сум, 2017 елда – 63 807,85 мең сум, 2018 елда – 75 181,55 мең сум, 2019 елда – 97 060,5 мең сум, 2020 елда – 69 177,65 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2016-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасында:

- программа паспортының 7 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 19884,35 | 63807,85 | 69366,95 | 97060,5 | 69177,65 | 319297,3 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | 5814,6 | - | - | 5814,6 |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 19884,35 | 63807,85 | 75181,55 | 97060,5 | 69177,65 | 325111,9 |
| | Искәрмә: Финанслау күләме прогноз характерына ия һәм тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. | | | | | | |

- программа чаралары системасын, шул исәптән еллар, чыганаклар буенча бүлеп, чаралар исемлеге һәм финанслау юнәлешләре булган программаны ресурслар белән тәэмин итүне яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Программа чаралары системасы, шул исәптән еллар, чыганаклар буенча бүлеп, чаралар исемлеге һәм финанслау юнәлешләре булган программаны ресурслар белән тәэмин итү

«2016-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау» шәһәр максатчан программасының программа чаралары системасы программага кушымтада күрсәтелгән.

2016-2020 елларга программаны финанслау күләме 325111,9 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет акчалары:

Чор өчен барлыгы 325111,9 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2016 елга – 19884,35 мең сум, 2017 елга – 63807,85 мең сум, 2018 елга – 75181,55 мең сум, 2019 елга – 97060,5 мең сум, 2020 елга – 69177,65 мең сум.»;

- программага кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2020 елның 25 февралендәге
851 номерлы карарына
кушымта

«2016-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлегендә җәмәгать
тәртибен тәэмин итү һәм хокук
бозуларны профилактикалау»
муниципаль программасына
кушымта

«2016-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау буенча эшчәнлекне камилләштерү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. Массакүләм мәгълүмат чараларында төрле җинаятьләрне һәм хокук бозуларны профилактикалау темасына социаль рекламаларны, социаль аудиовидеороликларны | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе, | атна саен | Шәһәрдә теркәлгән җинаятьләр саны, берәмлек | 7200 | 7000 | 6800 | 6600 | 6400 | 6200 | Чара оештыру характерына ия | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| регуляр трансляцияләүне оештыру | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2. Җинаятьчелеккә каршы тору буенча хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча халык белән очрашулар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | 2017-2020 | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| 1.3. Хокук саклау органнары хезмәткәрләре катнашында массакүләм мәгълүмат чаралары аша чит ил гражданнарының һәм гражданлык алмаган затларның хокук бозуларын профилактикалау һәм аларның РФ хокукый хәле, шул исәптән вакытлыча һәм даими яшәүгә рөхсәт алу, РФ гражданлыгы алу мәсьәләләре буенча аңлату эшләре үткәрү | Башкарма комитет мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге, Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | кимендә ярты елга бер тапкыр | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| 1.4. Алкогольле һәм спиртлы продукциянең легаль булмаган әйләнешенә, балигъ булмаганнарга тәмәке эшләнмәләре, алкогольле һәм спиртлы продукция сату фактларына чик куюга, контрафакт һәм фальсификацияләнгән товарларны әйләнештән алуга юнәлдерелгән профилактика чараларын гамәлгә ашыру | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | ел дәвамында | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| 2. Балигъ булмаганнар белән эшләүнең инновацион формаларын һәм методларын куллану, балалар һәм яшьләрне әхлакый һәм патриотик тәрбияләүне активлаштыру һәм камилләштерү | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. «Мәктәп татулашу хезмәте» проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | уку елы дәвамында | Балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләр саны, берәмлек | 280 | 280 | 260 | 240 | 220 | 200 | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| 2.2. Хокук бозуларны профилактикалау, хокукый аң формалаштыру, балаларны һәм яшүсмерләрне идея- | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | ел дәвамында | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| әхлакый тәрбияләү буенча тематик кинодәресләр (кинолекторийлар) үткәрү өчен муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләрендә киновидеофильмнар күрсәтүне оештыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.3. Полиция хезмәткәрләре катнашында «Полиция Кыш бабае» акциясе | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | декабрь 2016 | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | | | |
| | | | | | | | | | | 97,5 | - | - | - | - |
| 2.4. Балигъ булмаган гражданнарны каникул вакытында һәм укудан тыш вакытта эшкә урнаштыру | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2020 | | | | | | | | - | - | - | 7725,0 | - |
| 3. Хөкем ителгән затларны иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру (җәмгыятьтән изоляцияләмичә җәзага тартылган һәм шәһәрнең җинаять-башкару инспекцияләрендә исәптә торучы затларны ресоциализацияләү) | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. Мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җинаять җәзасы гамәлгә ашырыла торган оешмалар исемлеген һәм эш төрләрен билгеләү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | ел дәвамында | Тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санында элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган | 2500 | 2200 | 2000 | 1800 | 1600 | 1400 | Чара оештыру характерына ия | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| 3.2. Җинаять-башкару инспекцияләренең хезмәткәрләре белән берлектә җәмгыятьтән изоляцияләнмичә хөкем ителгән затлар белән тематик дәресләр, тренинглар үткәрү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | ел дәвамында | җинаятьләр саны, берәмлек | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| 3.3. Җинаять-башкару инспекцияләрендә исәптә торучы хөкем ителгән затларга һөнәри белем бирүне һәм һөнәри әзерләүне оештыру | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | ел дәвамында | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| 4. Җәмәгать иминлеген тәэмин итүдә эчке эшләр органнары эшчәнлеген оештыру һәм җәмәгать урыннарында хокук тәртибен һәм иминлекне тәэмин итү һәм җинаятьләрне ачу өчен заманча техник чаралар кертү | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.1. ТР «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Законы кысаларында җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү бурычларын хәл итү буенча, шулай ук хокук бозуларны | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | даими | Җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләр саны, берәмлек | 4200 | 4000 | 3800 | 3600 | 3400 | 3200 | Чара оештыру характерына ия | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| профилактикалауда үзара эшчәнлекне оештыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.2. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларын ТР Министрлар Кабинетының 2015 елның 388 номерлы карары белән расланган Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары төзүнең тәкъдим ителә торган критерийлары таләпләренә туры китерү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | даими | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| 5. Урамнарда хокук тәртибен тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.1. ТР «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Законы кысаларында гражданнарны, шул исәптән студентлар һәм эшләүче яшьләрне ирекле халык | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | даими | Шәһәр урамнарында 100 мең кешегә кылынган җинаятьләр саны, берәмлек | 2500 | 2300 | 2100 | 1900 | 1700 | 1500 | Чара оештыру характерына ия | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| дружиналарына җәлеп итү, яшьләр хокук саклау хәрәкәтен үстерү буенча эшне дәвам итү | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.2. Җәмәгать тәртибен саклауда ирекле катнашучы затларның дәвамлы эш тәҗрибәсен массакүләм мәгълүмат чараларында пропагандалауны гамәлгә ашыру | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | ай саен | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| 5.3. «Иң яхшы халык дружиначысы», «Иң яхшы халык дружинасы» конкурслары үткәрү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | ноябрь-декабрь ел саен | | | | | | | | - | 27,1 | 29,39 | 28,8 | 30,0 |
| 5.4. Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларын карап тоту | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2016-2020 | | | | | | | | 16001,85 | 57657,38 | 71502,51 | 83211,8 | 67328,22 |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| 5.5. «Здоровье» МАУ карап тоту | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | 2016-2017 | | | | | | | | 3785, 00 | 4808,94 | - | - | - |
| 5.6. «Закон территориясе» конкурсы документларын бастырып чыгару | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | һәр елның 1 кварталы | | | | | | | | - | 20 | 20 | 20 | 20 |
| 5.7. «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» шәһәр премиясе белән бүләкләүне үткәрү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | ярты елга 1 тапкыр | | | | | | | | - | 150 | 150 | 150 | 150 |
| 5.8. Яр Чаллы шәһәрендә җәмәгать тәртибен саклау буенча мәктәп, яшьләр һәм студентлар формированиеләре спартакиадаларын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | апрель ел саен | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| 5.9. Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр, студентлар һәм мәктәп формированиеләренең республика слетларында һәм конференцияләрендә катнашу | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | ел дәвамында | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| 5.10. Ел саен үткәрелә торган җәмәгать тәртибен саклау буенча иң яхшы яшьләр, эшчеләр, студентлар һәм мәктәп формированиесе республика конкурсында катнашу | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | сентябрь ел саен | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |
| 5.11. Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр, студентлар һәм мәктәп формированиеләре әгъзалары өчен сәламәтләндерү лагерьларында ел саен профильле сменалар оештыру | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | май ел саен | | | | | | | | Чара оештыру характерына ия | | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2014 (база) | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| 5.12. «Куркынычсыз шәһәр» АПК өчен элемтә каналлары хезмәте күрсәтү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | 2017-2020 | | | | | | | | - | 1144,43 | 3479,65 | 5924,9 | 1649,43 |
| барлыгы: | | | | | | | | | | 19884,35 | 63807,85 | 75181,55 | 97060,5 | 69177,65 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ